**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 9 февралендәге 383 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2018 елның 2 июлендәге 3783 номерлы**
**«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә**
**ярминкә операторын билгеләү буенча конкурс үткәрү турында**
**нигезләмәне раслау хакында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә эшчәнлекне дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 4 мартындагы 171 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре территориясендә ярминкәләр эшчәнлеген (аларда эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне) оештыруны тәртипкә салу максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 2 июлендәге 3783 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ярминкә операторын билгеләү буенча конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 26 июлендәге 2713 номерлы, 2020 елның 29 октябрендәге 3052 номерлы, 2021 елның 16 апрелендәге 915 номерлы, 2024 елның 17 декабрендәге 5211 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтада:

1.1.1. 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.3. Ярминкәдә товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен урыннар юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук гражданнарга (шул исәптән гражданнарга – крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларына, мондый хуҗалыклар әгъзаларына, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы, үз

ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүче гражданнарга) бирелә»;

1.1.2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ярминкә операторын билгеләү буенча конкурс үткәрү турында нигезләмәгә кушымтаның 2 таблицасындагы 3 пунктта «Конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары» баганасында «сәүдә» сүзе алдыннан «бер ярминкә көне өчен» сүзләрен өстәргә;

1.2. 3 номерлы кушымтада:

1.2.1. 2.1 пунктта 2.1.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1.1. әлеге шартнамә шартларының Оператор тарафыннан үтәлешен контрольдә тотарга. Шартнамә шартларын бозу очраклары ачыкланса, Вәкаләтле орган, хокук бозуны бетерү вакытын күрсәтеп, Операторга язмача хәбәрнамә юллый»;

1.2.2. 2.3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 2.3.20 пунктча белән тулыландырырга:

«2.3.20. Вәкаләтле орган шартнамә шартларын бозуларны ачыклаган очракта, Вәкаләтле орган язмача хәбәрнамә юллаган вакыттан алып 30 (утыз) календарь көн эчендә хокук бозуларны бетерергә»;

1.2.3. 4.2 пунктта:

1.2.3.1. 4.2.4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.2.4. Операторның әлеге шартнамәнең 2.3 пункты белән билгеләнгән шартларны үтәмәве»;

1.2.3.2. түбәндәге эчтәлекле 4.2.5 пунктча белән тулыландырырга:

«4.2.5. ярминкә операторын билгеләү буенча конкурска тәкъдим ителгән сайлап алу критерийларының Оператор тарафыннан үтәлмәве»;

1.2.3.3. түбәндәге эчтәлекле 4.2.6 пунктча белән тулыландырырга:

«4.2.6. гамәлдәге законнар белән каралган башка очраклар».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**